**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423752, село Чалманарат,
ул. Центральная,дом 2,
Тел. 3-44-64

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧАЛМАНАРАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

4235252, Чалманарат авылы,
Үзәк ур., 2 нчы йорт. Тел.3-44-64

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2021 ел №13

**Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының 20.06.2016 ел, №12 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3. Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Чалманарат авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Чалманарат авыл җирлеге
Советы рәисе К.С.Ахметов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОГРН 1021605557 Совет Чалманаратского сельского Поселения ИНН 1604001312